**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча
муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«16» июль 2021 ел** **№36**

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 11.1 номерлы карары белән расланган Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021елның 30 апрелендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. « Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 11.1 номерлы карары белән расланган Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибен һәм күләмнәрен билгели.».

Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре (алга таба - Хезмәткәрләр) дип муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затлары, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары булмаган вазифалар биләүче хезмәткәрләр, шулай ук Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче затлар аңлашыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Фәхретдинов